Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

№10 (140)

4 июнь 2015 ел

12+

## • Вакыйгалар эзеннән

**27 майда** А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтында чираттагы **РЕКТОР СЕМИНАРЫ** узды. Семинарда **ИЛШАТ ГАФУРОВ**, фәнни эшләр буенча проректор **ДАНИС НУРГАЛИЕВ**, инженерлык эшчәнлеге буенча проректор **НАИЛ КАШАПОВ**, Химия институты директоры **ВЛАДИМИР ГАЛКИН**, «Казаньоргсинтез» ачык акционерлык җәмгыятенең фән һәм инновацияләр буенча баш инженер урынбасары **ДАМИР САФИН** катнаштылар. Семинар «А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының Татарстан Республикасы сәнәгать оешмалары белән уртак эшчәнлеге» темасына багышланган иде. Илшат Гафуров КФУга мондый тәҗрибәнең гаять мөһим булуын ассызыклады. Дамир Сафин сүзләренә караганда, «Казаньоргсинтез» җәмгыяте КФУ белән тигез хокуклы хезмәттәшлек яклы.

• • • •

**29-30 майда** КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында **«ТАРИХИ ХӘТЕР ЯССЫЛЫГЫНДА КОНФЕССИЯАРА ЭШЧӘНЛЕК ТӘҖРИБӘСЕ»** дип исемләнгән фәнни конференция узды. Чарада Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган йөзгә якын дин тарихы галимнәре, социологлар һәм дәүләт эшлеклеләре катнашты. Аларга Татарстан Республикасының дәүләт киңәшчесе **МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ** сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте. Ике көн дәвамында хәзерге традицияләр һәм мәдәниятләр багланышын өйрәнүнең үсеш перспективасы турында сөйләшенде.

• • • •

КФУның Яр Чаллы институты **30 майда**, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, **«TWEED RUN»** дип аталган **ВЕЛОУЗЫШ** үткәрде. Әлеге чара сәламәт тормыш рәвеше алып баруга игътибарны арттыру, физик культура һәм спортны популярлаштыру максатыннан чыгып эшләнә, дип белдерделәр аны оештыручылар. Яр Чаллы шәһәренең Тынычлык проспектына җыелган 250 студент һәм администрация вәкилләре берничә сәгать дәвамында велосипедта шәһәр урамнарын урады.

• • • •

**1 июньдә** Физика институтының Гыйльми советы утырышы узды. Утырышның төп мәсьәләсе директор вазыйфаларын башкаручыны билгеләү булды. 2 июньдә Физика институты директоры **АЛЬБЕРТ ВАРТАН** улы **АГАНОВ**, директор вазыйфаларын башкару срогы чыгу белән бәйле рәвештә, киләчәктә үзен башка эштә сынап карарга теләвен белдерде һәм әлеге урынга конкурс нигезендә башка кешене билгеләүне сорады. Нәтиҗәдә, киләсе сайлауларга кадәр институт директоры вазыйфаларын **СЕРГЕЙ НИКИТИН** башкарачак.

• • • •

**1 июньдә** Казан университеты тарихы музеенда **«SPACEKAZAN-IAPS-2015»** дип исемләнгән Халыкара форумны ачу тантанасы узды. Чара астрономия буенча белем алучылар өчен КФУ, Россия Фәннәр академиясе, РФнең мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылды. Форум 1-7 июнь көннәрендә уза.

• • • •

КФУ белән Жозеф Фурье университетлары арасында үзара килешү турында **МЕМОРАНДУМ** төзелде. Рәсми документка Греноболь шәһәрендә урнашкан Жозеф Фурье университеты президенты **ПАТРИК ЛЕВИ** һәм КФУның тышкы эшләр буенча проректоры **ЛИНАР ЛАТЫПОВ** имзаларын куйдылар. Килешү квант электроникасы һәм радиоспектроскопия кафедрасы мөдире, профессор М.Таһиров һәм профессор Ю.Буньков тәкъдиме белән гамәлгә ашырылды. Очрашуда игътибар ителгән төп мәсьәләләр университетлар арасында алмашып уку һәм халыкара магистратуралар булдыру иде.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*




■ Алинә Хәйруллина Влад Михневский фотосында

# Уртак дус - профорг

«Ел профоргы-2015» бәйгесендә 1 нче урын, «КФУның студентлар лидеры» һәм «ТРның студентлар лидеры» бәйгеләрендә призлы урыннар яулаган Алинә Хәйруллина үзенең иң-иң яхшы профорг булуын күп тапкырлар дәлилләде.

● Фән дөньясында

# Төркиядә танылу алган татар галиме истәлегенә

Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында күренекле галим, тюрколог Р.Р.Аратның тууына 115 ел тулуга багышланган «Рәшит Рәхмәти Арат һәм төрки дөнья» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Бу чара Юныс Әмрә исемендәге Төркияне өйрәнү институтының Казандагы үзәге белән берлектә оештырылды.

Конференциянең тантаналы ачылышында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор **Рәдиф Рифкать** улы **Җамалетдинов**, Төркия Республикасының Казан шәһәрендәге Генераль консулы **Турхан Дильмач**, Юныс Әмрә исемендәге Төркияне өйрәнү институтының Казандагы үзәге җитәкчесе **Ихсан Демирбаш** сәламләү сүзе белән чыгыш ясадылар.

Конференциянең әһәмияте турында Турхан Дильмач шундый фикер янгыратты: «Мондый төр чараларны уздыру мөһим, чөнки төрки тел белеменә никадәр зур өлеш керткән булса да, Татарстанда да, Төркиядә дә Рәшит Рәхмәти Арат турында бернәрсә дә белмиләр диярлек». Чыннан да, бу галим күпләргә таныш түгел, аның хезмәтләре, фәнни иҗаты тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.



✦ Язмыш җиле **Рәшит Рәхмәти Аратны** 1933 нче елда Төркиягә китерә. Истанбул университетының төрки телләр һәм әдәбият кафедрасы профессоры булып эшли. Шунысы мөһим, ул 1949-1951 еллар аралыгында Лондон университетында тюркологиягә багышланган лекцияләр укый. Аннары, Истанбулга кайткач, университет каршындагы Тюркология институты директоры итеп билгеләнә. Галимнең төп фәнни хезмәте борынгы төрки әдәби ядкяр – Й.Баласагунлының «Котадгу белек» исемле әсәрен өйрәнүгә багышланган.

Конференциядә Казан галимнәре, Төркиянең төрле университетларыннан килгән профессорлар, Р.Р.Аратның якташлары катнашты. Алар галимнең фәнни эшчәнлеген, дөньякүләм тюркологиядәге урынын, хезмәтләренең төрки телләр өчен әһәмиятен бәян иттеләр. Гомуми лингвистика, лингвокультурология һәм тәрҗемә белеме кафедрасы доценты **Мәдинә Рәшит** кызы **Саттарова** әйтүенчә, конференциядә ясалган һәрбер чыгышны игътибар белән тыңларлык иде, чөнки яңа мәгълүмат һәрвакыт кызыклы.

Конференция программасы ике көнлек итеп төзелгән. 21 нче майда КФУ базасында фәнни сөйләшү уздырылса, 22 нче майда конференциядә катнашучылар Рәшит Рәхмәти Аратның туган ягы Әтнә районында булып кайттылар. Рәшит әфәнде туган Иске Өҗем авылында аның турындагы истәлекләрне кадерләп саклыйлар. Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге җитәкчесе **Әлфия Шәүкәт** кызы **Юсупова:** «*Р.Р.Аратның исеме авылда онытылмау – бик яхшы күренеш. Хәтер яшәсә, кеше исеме дә югалмаячак бит. Мәктәптә тюрколог истәлегенә мемориаль такта эленгән. Авыл халкы галимнең нәсел-нәсәбен барлап, шәҗәрәсен төзегән. Бу эштә Рәшит әфәнденең туганнары зур көч куйган*», – дип искәртте.

✦ **Рәшит Рәхмәти Арат** – төрки тел белемен Аурупа дәрәҗәсенә күтәргән шәхес, Истанбул университеты галиме, лингвист. Габдерәшит Исмәт улы Рәхмәтуллин 1900 елның 15 нче маенда хәзерге Әтнә районы Иске Өҗем авылында туган. 1920-22 елларда Кытайның Харбин шәһәрендә яши, «Ерак Шәрыкъ» газетасы редакциясендә эшли. 1922-1927 елларда Берлин университетында укый. Укуын тәмамлагач, шунда ук төрки телләр укыта һәм Берлин Фәннәр академиясендә эшли. 28 яшендә докторлык диссертациясен яклый.

● Шәхес

# Тарих һәм хәтер

Роза АСЫЛГӘРӘЕВА



Бу язмабызда халкыбыз алдында үз бурычларын намус белән үтәп, сугыштан соңгы мәгариф системасын нығытуга үзеннән зур өлеш керткән шәхесебез – Казан дәүләт педагогия институтының татар теле белеме кафедрасы доценты Зөһрә Мәҗит кызы Вәлиуллина турындагы фикерләребезне укучыларыбызга җиткерергә ниятләдек. Мәгарифебез үсешенә саллы өлеш керткән галим-методист, республикабызның күпсанлы укытучыларына яхшы таныш булган Зөһрә апа Вәлиуллинаның тормыш юлы һәм югары уку йортларында эшләү еллары бик бәрәкәтле, уңышлы булды. Аңа быел 90 яшь тулган булыр иде.

Зөһрә Мәҗит кызы Вәлиуллина 1925 нче елның 8 нче июнендә Башкортстанның Әлшәй районы Никифор авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туып үсә. Берничә ел узгач, алар гаиләләре белән Бәләбәй шәһәренә күчеп киләләр. Зөһрәнең балалык һәм мәктәп еллары шушы шәһәрдә уза. Мәктәптә яхшы укып, аны уңышлы тәмамлый, һәрвакыт белемгә омтыла, аз гына буш вакыты булса да, кулына китап алырга тырыша.

Тик авыр сугыш чоры яшь кыз алдына үз сораулары куя: кая барырга, кем булырга? Алар, дүрт кыз, әниләре янында, әтиләре – нык характерлы, эшчән һәм тырыш Мәҗит агай – көнне төнгә ялгап эштә, «барысы да – җиңү өчен, барысы да – фронт өчен!» дигән шигарьне чынга ашыручы. Мәҗит ага, кызы Зөһрәнең укудагы уңышларын күреп, аңа алга таба белем алырга кирәклеген аңлый һәм 1944 елда, кызына хәерфатихасын биреп, Саратов шәһәренә эвакуацияләнгән Ленинград дәүләт университетына озата. Монда Зөһрә Мәҗит кызы көнчыгыш телләр факультетын сайлый, төрки телләр белгечлеге буенча белем ала. Аның сабакташлары арасында соңыннан күренекле телче-галимнәр, тюркологлар була. Университетта уку елларында Зөһрә Мәҗит кызы төрек, француз, рус, фарсы, гарәп, азәрбайҗан, немец телләрен өйрәнә, диплом эшен «Татар телен өйрәнү тарихы» дигән темага язып, «бик яхшы» билгесенә яклый. 1949 елда ул, Ленинград дәүләт университетының көнчыгыш телләр факультетын тәмамлап, «лингвист-тюрколог» белгечлеген алып чыга.

Киң эрудицияле, белемгә омтылучан, фәнни эзләнүгә сәләте аермачык күренеп торган яшь белгечне 1949 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына аспирантурага тәкъдим итәләр. 1951 елда ул СССР Фәннәр академиясенең тел белеме институтына аспирантурасын дәвам итәргә җибәрелә. 1953 елда шул ук институтта «Татар теленең философик терминнары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый, татар теле белгечлеге буенча филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Зөһрә Мәҗит кызының шуннан соңгы бөтен тормышы тулысынча диярлек Казан дәүләт педагогика институты белән бәйле: 1953 нче елның августыннан башлап, ул республикабызга һәм башка төбәкләргә педагогик кадрлар әзерләүдә армый-талмый эшли: 40 ел дәвамында КДПИның тарих-филология факультетында «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» буенча лекцияләр укый, семинар дәресләр алып бара. Аның бу өлкәгә караган шактый күп санлы хезмәтләре дөнья күрә.



■ 1997 ел, фото автор архивыннан

Төрле елларда дөнья күргән әлеге хезмәтләр нәтиҗәсе буларак, 1972 нче елда З.М.Вәлиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» исемле зур күләмле китабы басылып чыга (К.З.Зиннәтуллина, М.Ә.Сәгыйтов белән автордашлыкта). Бу хезмәт шактый еллар буе галимнәр, студентлар һәм укытучылар өчен бик кирәкле, куллану өчен уңай дәреслекләрнең берсе булып кала бирә. 1972-1985 елларда 13 тапкыр басылып чыккан «Татар теле. 5 нче класс» дәреслеге (Д.Г.Тумашева белән авторлашлыкта) аның фәнни-методик эшчәнлегендә аерым урын алып тора.

Филология фәннәре кандидаты, доцент З.М.Вәлиуллинаның фәнни эшчәнлегенең икенче зур юнәлеше – рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнү. Нәтиҗәсе буларак, 1967 нче елда аның «Сопоставительная грамматика русского и татарского языков» исемле монографиясе дөнья күрә. Үзенең фәнни эзләнүләрен тулыландыра барып, Зөһрә Мәҗит кызы 1983 нче елда чагыштырма грамматиканың яңа басмасын чыгара. Анда татар һәм рус телләрендәге сүз ясалышы беренче тапкыр чагыштырып тикшерелә.

З.М.Вәлиуллина Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән «Татарская грамматика»ның икенче томын әзерләүдә якыннан катнашты. Ул бу китапның башта русча, аннан соң татарча басмасында исем сүз төркеменә караган материаллар авторы.

Зөһрә Мәҗит кызы, фәнни эшчәнлек белән бергә, җәмәгать тәртибендә үтәлә торган эшләрдә дә актив катнаша. 1961 нче елда партиянең Татарстан өлкә комитеты тәкъдиме буенча ул Казанда РСФСР Педагогия фәннәре академиясенең милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтын оештыру эшенә чакырыла һәм милли мәктәпләргә рус телен укыту методикасы белгече профессор Л.З.Шакирова, рус әдәбиятын укыту методикасы белгече доцент А.А.Михеева белән ике ел шунда эшли.

Зөһрә Мәҗит кызының фәнни-педагогик эшчәнлеге югары бәяләнде: ул 1968 елда «РСФСРның халык мәгарифе отличнигы», 1970 елда «В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә, 1975 елда «ТАССР мәктәпләренең атказанган укытучысы», 1976 елда «СССРның мәгариф отличнигы» исемнәренә, 1984 елда «Озак еллар буена намуслы хезмәт өчен Хезмәт Ветераны» медаленә лаек була.

Зөһрә апаның хезмәттәшләре, ул укыткан күпсанлы студентлар бүген дә, кадерле укытучыларының якты дөньядан китүенә дүрт ел тулуга карамастан, аның гаиләсенең язмышы белән даими кызыксынып, аңа булган хөрмәт, ярату хисләрен тормыш иптәше Гаяз абыйга, Зөһрә апаның яраткан оныкларына җиткереп торалар.

• Очрашу

# Гүзәл әхлак урнаштыру өчен килдем!

**Илсөяр ГАБИТОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм шәрыкъны өйрәнү институтының Исламны үстерү һәм ислам белеме бирү буенча «Исламика» ресурс үзәгендә Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев чыгыш ясады.



Аның лекциясендә ислам әхлагы һәм бүгенге җәмгыять мәсьәләләре кузгатылды. Җыелган студентлар арасында безнең уку йортыннан гына түгел, Россия ислам университеты шәкертләре дә бар иде. Дога белән башланган лекциянең татар телендә баруы күңелне тагын да җылытты.

Җәлил хәзрәт чыгышын Пәйгамбәребез (с.г.в.) сүзләреннән башлады: «Мин бу дөньяга гүзәл әхлакны тәмам урнаштыру өчен яратылдым». Һәрбер җәмгыять, дин өчен әхлак кануннары бер. Табигать кануннары, бөтен дөнья өчен бер булган кебек, кешелек кыйммәтләре дә бөтен Җир шары өчен уртак. Шуңа күрә аларны белү, үтәү һәрбер кешегә кагыйдә.

Без, әйләнә-тирәдә чишәсе проблемалар бик күп, дип әйтергә яратабыз, ул экология торышы да, эчкечелек, наркомания дә, шулай ук сугыш һәм төрле каршылыклар да. Әчынлыкта, бер генә проблема бар, дип белдерде хәзрәт, ул да булса – камил кеше тәрбияләү. Әгәр дә бөрәр гаилә үзеннән соң тәртипле бала калдыра ала икән, ул үзенең өе, гаиләсе, картлыгы, малы, мирасы өчен кайгырамы? Әлбәттә, юк. Ә бер конкрет алынган авылда барлык ата-ана да шундый балалар тәрбияләсә? Ул авылда проблема буламы? Уйлап карыйк, ә бөтен ил буенча гаиләләр балаларына дөрес тәрбия бирә алса? Проблемалар да юкка чыгар, киләчәк тә акыллы кешеләр кулына калыр иде.

Тәрбияле, гүзәл әхлаклы булу өчен, дүрт кагыйдәне белергә һәм үтәргә тырышырга кирәк, диде хәзрәт:

- Аллаһы Тәгаләне һәм ул яраткан барлык мәхлукларны ярату. Бөтен бәндәләрне аермасыз яратырга, аларга ярдәм итәргә тиеш, дигән сүз бу.
- Беркемгә дә зыян кылмаска. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Берәү начарлык кылса, яхшылык белән кайтар». Моны сабыр, иманы нык булган кешеләр генә үти ала. Шуңа күрә иманны үстерергә, үз өстеңдә эшли белергә кирәк.
- Аллаһы Тәгалә биргәнгә риза булу, канәгать булу һәм шөкер кылу. Дөньядагы иң зур байлык – канәгатьлек. Безнең дөньяда кеше акча артыннан куа, һаман шуннан бәхет тапмакчы була. Ә ул акчага тынычлык та, бәхет тә, сәламәтлек тә сатып алып булмый. Булганына риза, канәгать кеше иң бәхетле һәм бай.
- Кирәкмәгән җиргә борын тыкмаска. Монысы белемсез кешеләрнең башкаларны өйрәтергә тырышуын тәнкыйтьләүгә нигезләнә. Ягъни башкаларны өйрәтергә алынганчы, башта үзең ныклап белем үзләштер.

Лекцияне студентлар тын да алмыйча тыңлады, чөнки әхлак мәсьәләсе һәрберебезне борчый, ә Җәлил хәзрәт тормыштан гыйбрәтле хәлләрне мисалга китереп, бик тәэсирле итеп сөйләде. Мондый әхлакка бәйле лекцияләрне студентларны укыту программаларына кертсәләр дә комачауламас иде, дигән фикергә килдем.

• Уңыш сере

# Уртак дус – профорг

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

Лекциядә каләмең язудан туктаса яки укытучы биргән сорауга җавапны белмәсәң, янәшәңдә утыручы дустың ярдәмгә килер. Ә катлаулырак проблемалар очраса, нишләргә, кемгә мөрәҗәгать итәргә? Әлбәттә инде, студентларның уртак дусты – профоргка!



Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар филологиясе бүлеге студентлары профсоюзы җитәкчесе **Алинә Хәйруллина** үзенең КФУ профорглары арасында иң-иң булуын күп тапкырлар дәлилләде инде: ул быел «Ел профоргы» бәйгесендә 1 нче урын алды, моннан тыш «КФУның студентлар лидеры» һәм «ТРның студентлар лидеры» конкурсларында катнашып, 2 нче һәм 1 нче урыннар яулады.

– Быелгы укуелы минем өчен вакыйгаларга бик бай булды. 2014 нче елда ныклап торып бүлегебезнең профоргы вазыйфаларына керештем, студентлар белән аралашу тәҗрибәм шактый артты. Кешеләр белән эшләү серләрен үзләштердем, авырлыкларны һәм алардан чыгу юлларын күрә белергә өйрәндем.

**– Алинә, «Ел профоргы», «КФУның студентлар лидеры», «ТРның студентлар лидеры» бәйгеләре нәрсә белән истә калды?**

– «Ел профоргы» минем өчен старт мәйданчыгы булды. Тәҗрибәм җитәрлек түгелдер дип бик борчылдым, шуңа күрә бәйгегә әзерлек өлешенә зур игътибар бирдем. Бик күп норматив документлар белән кабаттан танышып, аңа өстәмә рәвештә өйрәнеп чыгарга туры килде. Әлеге конкурс шуның белән истәлекле. Калган бәйгеләргә әзерләнгәндә исә, беренче карашка кечкенә кебек тоелган проблеманы закон ярдәмендә чишәргә өйрәнү процессы ныграк хәтергә сеңеп калды. Хәзер, нинди генә авыр ситуация белән очрашсам да, законга мөрәҗәгать итәм. Бу шәхсән үзем өчен дә бик файдалы булды.

Һәрвакытта да янәшәңдә терәк булырлык кешеләр кирәк. Әзерләнү барышында да, бәйгеләр вакытында да миңа әнием һәм остазым – Юлия Владимир кызы Виноградова зур ярдәм күрсәтте. Аларның янәшәмдә булуы, минем өчен җан атып торулары – онытылмаслык.

**– Студентларны күбрәк нәрсә борчый?**

– Безнең белән бергә укучылар арасында тулы булмаган яки күп балалы гаиләдән килүчеләр шактый. Профсоюз оешмасы билгеле бер категориягә караган студентларга ай дәвамында бушка төшке аш алу мөмкинлеге бирә. Гадәттә, шушы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәләр һәм социаль ярдәм алырга булышуны сорыйлар.

**– Профорг булып эшләү тәҗрибәңдә булган иң авыр очрак нинди?**

– Һәрбер кешенең тормышында авыр ситуацияләр булырга мөмкин: иң куркынычы – ул этиәнине югалту яки яман авыруларга дучар булу. Күптән түгел әнисен югалткан студент кызга ярдәм итәргә туры килде. Зур хәсрәт кичерә торган кешегә дөрес сүзләр табып мөрәҗәгать итү, кайгысын уртаклаша белү дә бик мөһим. Тиешле документлар туплап, студентка матди ярдәм, социаль стипендия алырга булыштык. Иң авыры «Әниеңнең үлеме турында таныклык алып кил әле», – дигән сүз булгандыр, мөгаен. Узган уку елында, әле мин профорг ярдәмчесе булып йөргәндә, институтыбызда укый торган бер студентыбыз яман шеш авыруы белән йөзгә-йөз очрашты. Махсус курслар узу, кыйбатлы дарулар алу өчен акча җыю белән шөгыльләндек. Профорг эшендә иң авыры – алтын урталык табу: кешеләргә карата ихлас булырга, аларның кайгыларын йөрәгең аша үткәрергә, шул ук вакытта, аек акыл белән эш итә белергә дә кирәк.

**– Профсоюз оешмасының җитешсез яклары бармы? Син нинди үзгәрешләр кертер идең?**

– Университетыбызның профсоюз эшчәнлеге, башка регионнар белән чагыштырганда, күпкә алда һәм аннан нинди дә булса җитешсезлек табу мөмкин түгел, миңа калса. Үзгәрешләргә килгәндә, студентларның тормышын алга җибәрүгә корылган яңа проектлар тәкъдим итәргә булыр иде. Мәсәлән, хыялымда йөри торган бер чара бар. Ул да булса, «Мин профсоюзны сайлыйм!» атналыгы. Әлеге чара беренче һәм икенче курс студентларына йөз тотып оештырылыр, шул ук вакытта профсоюз белән кызыксынган теләсә кайсы студент атналыкта үз көчен сынап карый алыр иде. Биредә профсоюз өлкәсенә кагыла торган мастер-класс яки психологик тренинглар уздырырга була. Минемчә, профорглар турыдан-туры психологлар белән эшләргә тиеш. Чөнки профорг ул авыр хәлдә калган студентларга акчалата ярдәм алырга булышучы гына түгел, ә киңәшче, терәк тә.

Күз алдына китереп карагыз, яңа гына якын туганын югалткан студент университетта беренче булып профорг янына килә. Мондый очракта коры гына: «Кирәкле документларыңны алып кил, бер айдан матди ярдәм булыр», – дип әйтеп булмый. Һәркемгә аерым якын килә белергә өйрәнергә кирәк.

Шундый атналыкта иң актив катнашкан студентларның рейтингын төзеп, аларны вуз, институт, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнаштырырга мөмкин булыр иде. Шулай ук профсоюзның абруен арттыруга юнәлдерелгән акцияләр уздырырга да хыялланам.

**– Идеаль профорг. Нинди ул?**

– Әйткән сүзен, вәгъдәсен эше белән дәлилләгән, әйләнә-тирәдәгеләргә хәерхаһлы булган, профсоюзны үз гаиләсе кебек яраткан, хөрмәт иткән һәр профорг – идеал. Миңа калса, ул бер хыял белән яши: университетыбызга яңа килгән студентларга вакытында ярдәм кулы сузу, профсоюз оешмасының асылын күрсәтү, аңа карата кызыксыну хисе уяту. Хәзерге вакытта минем алда торган иң зур максат – үземнән соң тиешле дәрәҗәдә эшләрлек алмаш тәрбияләү. Минем дә чыгарылыш имтиханнарын бирәсе көннәрем якынлаша бит инде.

**– «Хәзер син дөньядагы барлык студентларга мөрәҗәгать итә аласың», – дисәләр, нәрсә әйтер идең?**

– Тормышта үзеңне табыйм дисәң, үз-үзеңне үстерү өстендә эшләү гаять мөһим.

Укырга кая гына барам дисән дә, син, һичшиксез, мөстәкыйль тормышка иярләшергә туры киләчәк. Тулай торактамы син, йә булмаса фатирдамы – барыбер үз янәшәңдәге кешеләр белән уртак тел табарга тырышырга кирәк.

# Тулай торак серләре

**Гүзәл АСЫЛОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Университетка читтән килеп укучыларның яртысыннан күбрәге тулай торакта яши. Мин дә, дүрт ел элек Казанга укырга килгәч, әлеге «баскычны» үттем. Бу – өең түгел инде: тәмле ашлары белән әниең көтеп тормый, «Балам, арыгансыңдыр, ял ит», – диюче дә юк. Барысын да үзеңә эшләргә туры килә. Әле дә исемдә, миннән зуррак иптәшләрем: «Йомырка булса да кыздырыйм дип, уртак кухняга чыксаң, газ плитәсе буш түгел; авыр көннән соң мендәргә башыңны төртүгә, стена артында музыка уйный башлый... Кая барасың, түзәсең инде. Бер күзең белән плитә бушаганын, икенчесе белән душка чират беткәнен чамалап торасың», – дип куркытып куйганнар иде. Ләкин, минем бәхеткә, мондый авырлыклар белән очрашырга язмады. Чөнки безгә Универсиада авылыннан яңа, чиста, киң бүлмәләр бирделәр. Шуңа да карамастан, тулай торак кайда да тулай торак инде. Гомумән, анда яшәүнең үз тәртибе, үз кагыйдәләре бар.

Иң элек, кирәкле гаризаларны, белешмәләрне тапшыргач, сиңа бүлмәнең ачкычы бирелә. Кастелянша сиңа урын-җир әйберләрен тапшыра һәм исеңдә калдыр: тулай торактан киткәнче, алар синең җаваплылыгыңда булачак! Мөһим мәсьәләләрнең берсе – комендант һәм вахтада утыручы абый-апалар белән уртак тел табу. Бу ни өчен кирәк дисеңме? Анысын инде төннәрен соңга калып кайтканда аңлый башлыйсың. Монда дипломатик сәләтеңне үстерү комачауламас, ә кемнең нинди шоколад яратуын белү файдага гына булыр.

Вакытлар узу белән, тулай торак пешерергә дә өйрәтә. Кулинарлык серләрен үзләштергәнче исә, бүлмәдәшең пешерә тора, ә син, ашагач, савыт-сабаны юып куясың. Күрше бүлмәдән тәмле коймак, кызган бәрәңге исе килсә, «ялгыш» кына хәлләрен белергә кереп чыксаң да була.

Тулай торак тормышына һәр кеше үзенчә күнегә. Тик нәкъ менә шунда гына син якын дус, сабырлык, аралашу, мөстәкыйльлек кебек төшенчәләрне аңлый башлыйсың.

● Сәнгать

ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ДӨНЬЯСЫ, АНДА БАРГАН ВАКЫЙГАЛАР, ТӨРЛЕ РУХТАГЫ МИЛЛИ ХӘРӘКӘТЛӘР ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ ДАИМИ ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ. УЗГАН САННАРЫБЫЗНЫҢ БЕРСЕНДӘ МИЛЛИ КИЕМ ЖИТЕШТЕРҮ ТУРЫНДА ЯЗМА БУЛАЧАГЫН ВӘГЪДӘ ИТКӘН ИДЕК. ВӘГЪДӘБЕЗДӘ ТОРАБЫЗ: КАРШЫ АЛЫГЫЗ, ПОДИУМДА – ТАТАР МОДАСЫ.

# Миллилек брендка әйләнерме?

Күзәтүне **Руфинә Габдрахманова** ясады

Заманча киенергә яратучылар Dolce & Gabbana, Prada брендлары белән мавыккан бер дәвердә халыкның ерак гасырлардан ук килгән тормыш итү үзенчәлеген, милли рухны саклап калу кыен сыман тоела. Сүзем күңел халәте турында түгел, тышкы кыяфәт турында.

Хәзерге кием индустриясенә яңалык алып килү, гадәттә, күз алдына да китерә алмаслык образлар тәкъдим итүгә кайтып кала. Еш кына, моданың ни халәттә булуын күзәтәсе килеп, интернет сәхифәләрен актарабыз. Һәм... шаккатабыз. Нигә дисезме? Сере гади: мода дөньясында исемнәре үк бренд кебек яңгыраган модельерларның кием коллекцияләре көнкүреш өчен бөтенләй яраксыз булып күренә. Чынлап та, моннан асылынган, тегеннән ертылган күлмәк-чалбарларны кайда гына киеп була икән?!

Әйләнә-тирәгездә татар бизәкләре төшерелгән киемле яшьләрне күрсәгез, аптырамагыз: милли мода бүген чын мәгънәсендә яңарыш кичерә. Татар нәкыше кабат көнкүрешкә кайта! Шунысы куандыра: дәүләт заказы нигезендә башкарылган эш түгел бу. Әлеге шаукымның башында, беренче чиратта, тынгы белмәс яшьләр тора. Егет-кызларның милли тамырларга тартылуы аларның шәхси мавыгулары белән аңлатыла. Берәүләр үз гардеробында татар орнаментлары белән бизәлгән киемнәрне күрергә теләсә, икенчеләре – әлеге продукцияне уйлап табып, милли мода турындагы хыялын гамәлгә ашырырга омтыла.

Интернеттагы «vkontakte.ru» сайты кысаларында гына тәкъдим ителүдән башланып киткән татар киеме проектлары, аларның дизайнерлары хәзерге көндә зур тизлек белән популярлык казана. Мондый кискен алгарышның төп сәбәбе татар яшьләренең миллилеккә сусавында. Син дә шундый «сусаган» егет-кызларның берсе икәнсең, алдагы мәгълүматлар синең өчен.



## «MISA»

Татар дигән милләтебез бар икәнен белдерә торган заманча милли кием булдыру проектлары рәтендә «MISA» коллекциясе күренекле урын алып тора. Аның башында – КФУда белем алган дизайнер кыз **Миләүшә Мусина**. Үзен һәрвакыт авыл баласы дип танытучы бу кыз бүгенге көндә татар милли киемнәре тегә, калфак-түбәтәйләр чигә, заказлар кабул итеп, аларны сатуга чыгара. «Милли кием – халкыбыз рухын саклаган мирас», – ди ул. Миләүшә бүгенге көндә милли мотивлар белән бизәлгән күлмәкләр тегү белән дә шөгыльләнә, үз ательесын ачуга ирешкән.

«MISA» коллекцияләре белән vk.com/atelier_misa адресы буенча урнашкан сәхифәдә таныша аласыз.



## «Мирасыбызны саклап»



Матурлык ул – иң беренче чиратта, житди тырышлык нәтиҗәсе. Аңа ирешү өчен, еллар, гасырлар кирәк. Кичә матур булган әйбер бүген инде гадәти бер күренеш булып кала һәм икенче бер яңа эталон белән алышына. Ә элеккегене, «иске»не, яңартып, популярлаштырып, бүгенге трендка әйләндереп буламы? Була икән!

Үз эшчәнлеген 2013 нче елдан башлаган «Мирасыбызны саклап» проектының миссиясе – татар нәкыш сәнгатенең, бизәк-орнаментларының инде онытыла башлаган матурлыгын кире кайтару. Проектка нигез салучы – дизайнер, рәссам **Ренат Сәфәров**. Ул халкыбызның борынгы бизәк төшерү сәнгатенә яңа заман сулышы өреп, аны яңача аңлатуга ирешкән. Декоратив сәнгать элекке заманда бизәнү әйберләрендә, милли киемдә, сөлге, тукыма чигүдә чагылган булса, хәзер ул Iphone өчен тышлык, зәвыклы бизәк төшерелгән футболка-майка, блокнот, котлау открыткалары буларак кулланылышка кереп бара. Шулай ук бу проект катнашучылары тәкъдим иткән продукция арасында балалар өчен рәсем буяу китаплары, картиналар да табарга була. «МС» продуктлары кызыксындырса, renatsafarov.ru һәм vk.com/tat_design интернет адреслары буенча кереп, алар турында мәгълүмат табарсыз.




## «Милли кием»

«Үзен бөек милләт әһеле дип хис итүчеләр өчен заманча, уңайлы кием» тәкъдим иткән тагын бер проект әле күптән түгел генә кием индустриясенә килеп керде. «Милли кием» проектының җитәкчесе **Илшат Хәйретдинов** татар бизәгенең эстетик зәвыгын көндәлек тормышка кайтаруны максат итеп куя, өс киеменә ул рухи мирасны чагылдыручы матди мәдәният атрибуты итеп карый. Ул ир-егет һәм хатын-кызлар өчен, көндәлек кием буларак, татар футболкалары тәкъдим итә. Уңайлы, сыйфатлы, заманча футболкаларга заказны «Вконтакте» социаль челтәрендәге vk.com/millikiem адресы буенча теркәлгән берләшмә аша бирергә мөмкин.



## «Татарча CASUAL»

«Татарча CASUAL» проекты да милли мода өлкәсендә беренче адымнарын кыю ясый. 2013 нче елда идея буларак кына яшәгән уйлар, хыяллар бер ел эчендә **Айгөл Сөнгатуллина** һәм **Мира Рәхмәт** тарафыннан тормышка ашырыла. Беренче коллекция «Бөтендөнья татар яшьләре форумы»нда тәкъдим ителә. Танылу шул чордан башлана. Кызлар, татар бизәге традицияләрен дөнья модасы белән бәйләп, свитшот, күлмәк, итәк, пәлтә, сумка, аяк киемнәре иҗат итәләр. Татар дөньясында милли модага бәйле шаукымны нәкъ шушы коллекция тудыра. Берәү аларны зәвыклы, матур, заманча дип тапса, икенчеләре татар киеме мондый була алмый, дигән тәнкыйть белән чыга. Ләкин «Татарча CASUAL» проекты бер урында гына тормый. Анда катнашучылар һаман эзләнүдә. Яңадан-яңа, матурдан-матур киемнәр тәкъдим итеп, алар татар яшьләрен, аеруча кызларны, бик сөендерәләр. Соңгы көннәрдә генә бу проект эчендә тагын бер яңалык туды: ул – балалар өчен «Олы ефәк юлы» дип исемләнгән татарча җәйге киемнәр коллекциясе. Бу һәм башка коллекцияләрне интернетта vk.com/tatarchacasual һәм tatarchacasual.com сайтларында табарга мөмкин.

***Фотолар социаль челтәрләрдәге төркемнәрдән алынды.***

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.